| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.07.2018 ел Баулы шәһәре № 163

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органына буйсынган оешма җитәкчесенең вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яки китерерлек шәхси кызыксыну тууы хакында хәбәр итү тәртибе турында

Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, ФЗ-131 нче Федераль закон, "Коррупциягә каршы тору" 2008 ел, 25 декабрь, ФЗ-273нче Федераль закон, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы уставы нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органына буйсынган оешма җитәкчесенең вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерерлек шәхси кызыксыну тууы хакында хәбәр итү тәртибен расларга (Кушымта).

2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарына:

2.1. ведомствога караган оешмалар (учреждениеләр) җитәкчеләрен әлеге карар белән таныштырырга;

2.2 җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмалар (учреждениеләр) уставларына, шулай ук аларның җитәкчеләре белән төзелгән хезмәт килешүләренә җирле үзидарә органына буйсынган оешма җитәкчесенең

вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерерлек шәхси кызыксну туууы хакында хәбәр итү бурычын йөкләү турында үзгәрешләр кертергә;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны үтәүне тикшерүне Баулы муниципаль башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы рәисе

АППАРАТ СОВЕТА
СОВЕТ АППАРАТЫ

Р.Х. Гатиятуллин

Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы
Советының 2018 ел, 3
июльдә кабул ителгән
163нче санлы карарына
кушымта

## Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарына буйсынган оешма (учрждение) җитәкчесенең вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерерлек шәхси кызыксыну туувы хакында хәбәр итү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарына буйсынган оешма (учрждение) җитәкчесенең вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерерлек шәхси кызыксыну туувы хакында хәбәр итү процедурасын билгели.

2. Әлеге Тәртиптә мәнфәгатьләр каршылыгы дигәнне вазифаи бурычлары кызыксынулар каршылыгын булдырмауны яки җайга салуны күздә тоткан вазифаи затның шәхси кызыксынулары үз хезмәт бурычларын тиешенчә, объектив, гадел үтәүгә (үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга) комачаулаучы яки комачауларлык ситуация дип аңларга кирәк.

3. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарына буйсынган оешма (учреждение) җитәкчесе Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору турынагы закончалыгы һәм оешма (учреждение) уставы нигезендә мәнфәгатьләр каршылыгы турында хәбәр итәргә һәм шулай ук аларны булдырмау яки җайга салу чараларын күрергә тиеш.

4. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарына буйсынган оешма (учреждение) җитәкчесе вазифаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерерлек шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында эш бирүчегә (эшкә алучының вәкиленә) моның турында белгәннән соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә бурычлы.

5. Җирле үзидарә органнарына буйсынган оешма (учреждение) җитәкчесенең вазифаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерерлек шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында әлеге Тәртипнең 4нче пунктында каралган срокта, аңа бәйле булмаган сәбәпләр буенча, хәбәр итү мөмкинлеге булмаса, ул андый сәбәп бетерелгәннең икенче көненнән (эш көненнән) дә соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

6. Хәбәр язмача, вазифаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерерлек шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында хәбәрнамә (алда – хәбәрнамә) буларак рәсмиләштерелә.

Хәбәрнамәдә түбәндәге мәгълүмат күрсәтелә:

а) хәбәрнамәне тутырган җирле үзидарә органнарына буйсынган

оешма (учреждение) җитәкчесенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, биләгән вазифасы;

б) җирле үзидарә органнарына буйсынган оешма (учреждение) җитәкчесенең шәхси кызыксынуы (турыдан-туры яки читтән) үз хезмәт бурычларын тиешенчә, объектив, гадел үтәүгә комачаулаучы яки комачауларлык хәлне тасвирлау;

в) җирле үзидарә органнарына буйсынган оешма (учреждение) җитәкчесенең хезмәт бурычларын тиешенчә үтәүгә комачау итүче яки комачауларлык шәхси кызыксынуын күрсәтүче билгеләр (оешма җитәкчесенең яки аның якын туганнарының (үзенең яки тормыш иптәшенең ата-анасы, бертуганнары, балалары яки балаларның тормыш иптәшләре), оешма җитәкчесе яки аның якын туганнары милек, корпоратив яки башка мөнәсәбәтләр белән бәйле затларның акча, башка милек рәвешендә керем, шул исәптән милек белән бәйле хокук, хезмәт күрсәтү, башкарылган эшләр нәтиҗәсе яки башка төрле файда алу мөмкинлеге)

г) шәхси кызыксыну үтәлешенә тискәре йогынты ясаучы яки ясарлык вазифаи бурычларны тавирлау;

д) мәнфәгатьләр каршылыгы килеп тууына юл куймаслык яки барлыкка килгән мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салырлык чараны тәкъдим итү;

е) хәбәрнамәне тутыру датасы;

ж) хәбәрнамәне тутырган затның имзасы.

7. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарына буйсынган оешма (учреждение) җитәкчесе эш бирүчегә (эшкә алучының вәкиленә) 1нче санлы кушымтадагы форма буенча тутырылган хәбәрнамә җибәрә.

8. Эш бирүчегә (эшкә алучының вәкиленә) кергән хәбәрнамәләр Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Хезмәт (вазифаи) тәртибенә карата куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясенә (алга таба – Комисссия) тапшырыла.

9. Хәбәрнамәне Комиссия сәркатибе хәбәрнамәләр теркәү журналында әлеге Тәртипнең икенче кушымтасында күрсәтелгән үрнәктә терки.

Комиссия сәркатибе хәбәрнамәдәге мәгълүматны чит затларга белгертергә тиеш түгел. Мәгълүматны чит затларга белгерткән кеше Россия Федерациясе законнчалыгы нигезендә дисциплинар һәм башка җаваплылыкка тартыла.

10. Хәбәрнамәнең теркәү билгесе куелган күчермәсе Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарына буйсынган оешма (учреждение) җитәкчесенә теркәү журналына имза куйдыртып бирелә яки почта аша (тапшыру турында хәбәрнәмә белән) җибәрелә.

11. Башлангыч тикшерү барышында Комиссия хәбәрнамә җибәргән кешедән хәлне тасвирлаучы аңлатмалар алырга һәм билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте федераль органнарына, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм тиешле оешмаларга сораулар җибәрергә хокуклы.

12. Хәбәрнамәне башлангыч тикшерү нәтиҗәләре буенча һәрберсенә нигезле бәяләмә әзерләнә.

Хәбәрнамәләр, бәяләмәләр һәм хәбәрнамәне башлангыч тикшерү вакытында алынган башка материаллар хәбәрнамә кергәннән соң җиде эш көне эчендә Комиссия утырышында тәкъдим ителә.

Әлеге Тәртипнең 11нче пунктында күрсәтелгән сораулар җибәрелгән очракта, хәбәрнамәләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар Комиссиягә хәбәрнамә эш бирүчегә (эшкә алучының вәкиленә) кергәннән соң 45 көн эчендә тәкъдим ителә. Әлеге срок озынайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән дә артыграк вакытка түгел.

13. Комиссия хәбәрнамәне тикшерә һәм алар буенча Комиссия турындагы положениедә каралган тәртиптә карарлар кабул итә һәм аны эш бирүчегә (эшкә алучының вәкиленә) җибәрә.

14. Эш бирүче (эшкә алучының вәкиле) Комиссия хәбәрнамәне тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) хәбәрнамә юллаган зат вазифаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы тумый дип таный;

б) хәбәрнамә юллаган затның, вазифаи бурычларын үтәгәндә, шәхси кызыксынуы мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин дип таный;

в) хәбәрнамә юллаган затның мәнфәгатьләр каршылыгына юл куймавын яки аларны җайга салмавын таный.

15. Әлеге Тәртипнең 14нче пунктының “б” подпунктында каралган карар кабул ителгән очракта, Россия Федерациясе закончалыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарына буйсынган оешма (учреждение) җитәкчесе мәнфәгатьләр каршылыгына юл куймау яки аларны җайга салу чарасын күрә яки андый чаралар күрелүен тәэмин итә.

16. Әлеге Тәртипнең 14нче пунктының “в” подпунктында каралган карар кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарына буйсынган оешма (учреждение) җитәкчесенә карата Россия Федерациясе хезмәт кодексында, җирле үзидарә органнарына буйсынган оешма (учреждение) уставында һәм хезмәт килешүендә каралган дисциплинар җәза кулланыла.

Хәбәрнамә һәм аны тикшерү белән бәйле башка материаллар Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарына буйсынган оешма (учреждение) җитәкчесе шәхси эшенә кертелә.

Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы
җирле үзидарә органына буйсынган оешма
(учреждение) җитәкчесенең вазифаи
бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр
каршылыгына китерүче яки китерерлек
шәхси кызыксыну
тууы хакында хәбәр итү тәртибенә
1 нче санлы кушымта

*Киңәш ителгән үрнәк*

______________________________
Вәкиллекле орган рәисенә,
Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесенә
(туры килгәнен сайларга)
__________________________________ка
(Ф.И.О.)

___________________________________
(Ф.И.О., вазифа)

**Вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр**
**каршылыгына китерүче яки китерерлек шәхси кызыксыну**
**тууы хакында**
**ХӘБӘРНАМӘ**

Вазифаи бурычларымны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яки китерерлек (туры килгәненең астына сызырга) шәхси кызыксынуым барлыкка килүе турында хәбәр итәм.

Шәхси кызыксыну тууга нигез булдыручы шартлар

______________________________________________________________________

Шәхси кызыксыну йогынты ясаучы яки ясарга мөмкин вазифаи бурычлар: _________________________________

____________________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр каршылыгына юл куймау яки аларны җайга салу буенча тәкъдим ителгән чаралар

______________________________________________________

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Комиссиясе әлеге хәбәрнамәне тикшергәндә катнашырга ниятлим (катнашмыйм) (туры килгәненең астына сызарга)

«_____» _________ 20__ ел.
(хәбәрнамәне юллаган затның имзасы) (имзаның расшифровкасы)

Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы
җирле үзидарә органына буйсынган оешма
(учреждение) җитәкчесенең вазифаи
бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр
каршылыгына китерүче яки китерерлек
шәхси кызыксыну
тууы хакында хәбәр итү тәртибенә
2 нче санлы кушымта

Киңәш ителгән үрнәк

## Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органына буйсынган оешма (учреждение) җитәкчесенең эш бирүчегә (эшкә алучы вәкиленә) вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яки китерерлек шәхси кызыксыну тууы хакында хәбәр итүен теркәү журналы

| N п/п | Хәбәрнамәнең теркәү номеры | Хәбәрнамәне теркәү көне | Хәбәрнамәне юллаучы | | Хәбәрнамәне теркәүче | | | Хәбәрнамәнең күчермәсен алу турында билге (күчермәне алдым, имза) яки күчермәне почта аша юллау турында |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ф.И.О. | вазифасы | Ф.И.О. | вазифа | имза | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |